ГЛАВА ЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д.9, с. Нижние Яки,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422157

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яңа ур., 9 нче йорт, Түбән Яке авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422157

тел.(факс): (85563) 2-94-38; e-mail: Yak.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
" 29" октябрь 2019 ел

Постановление
№ 6

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлегенең Түбән Яке авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Яке авыл җирлеге муниципаль берәмлеге" Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Түбән Яке авылы , Ленин урамы , 50 нче йорт адресы буенча урнашкан Түбән Яке авылы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 13 ноябрендә сәгать 14.00 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлегенең Түбән Яке авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлегенең Түбән Яке торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Түбән Яке авылында, Г. Тукая урамына   вак таш җәю ( сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча түләү).

-Түбән Яке торак пунктындагы  юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ»                                   «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге башкарма комитетына Түбән Яке авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә  муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар  басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Яке авыл җирлеге башлыгы:                                   Р.К.Низаметдинов